МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№ 95/о

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«05» 05 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча коммуналь хезмәтләр куллану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм гомуми милекне карап тоту мәсьәләләре турында» 2016 елның 26 декабрендәге 1498 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында коммуналь хезмәтләр куллану нормативларын һәм коммуналь ресурслар куллану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 313 номерлы карары нигезендә б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы һәм торак йортларда салкын, кайнар су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча коммуналь хезмәтләр куллану нормативларын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 20 маендагы 62/о номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

беренче абзацта «2012 елның 1 сентябре» сүзләрен «2017 елның 1 июне» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «күпфатирлы йортларда йортның гомуми ихтыяҗларына салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү хезмәтләрен» сүзләрен «күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында салкын һәм кайнар су ресурсларын» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «йортның гомуми ихтыяҗларына салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр куллану нормативлары» сүзләрен «күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында салкын һәм кайнар суның коммуналь ресурсларын куллану нормативлары» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы йортларда йортның гомуми ихтыяҗлары өчен салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр куллану нормативларын яңа редакциясендә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Бу боерык 2017 елның 1 июненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.М.Фроловка йөкләргә.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2012 елның 21 августындагы 131/о номерлы боерыгы
(Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2017 елның «05» 05 95/о номерлы боерыгы редакциясендә белән расланды)

## Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәрләре) өчен күпфатирлы йортларда йортның гомуми ихтыяҗларына салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү буенча коммуналь хезмәтләр куллану нормативлары

күпфатирлы йортта гомуми милек составына керә торган биналарның гомуми мәйданының бер кв. метрына аена куб. метр

| № | Торак биналарның категориясе | Катлар саны | Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында салкын су куллану нормативлары | Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында кайнар су куллану нормативлары |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Салкын һәм кайнар су белән тәэмин итү, су бүлү үзәкләштерелгән күпфатирлы йортлар | 1дән 5кә кадәр | 0,03 | 0,03 |
| | | 6дан 9га кадәр | 0,02 | 0,02 |
| | | 10нан 16га кадәр | 0,02 | 0,02 |
| | | 16дан артык | 0,02 | 0,02 |
| 2. | Салкын су белән тәэмин итү үзәкләштерелгән, су җылыт-кычлары, су бүлүе булган күпфатирлы йортлар | 1дән 5кә кадәр | 0,03 | X |
| | | 6дан 9га кадәр | 0,02 | X |
| | | 10нан 16га кадәр | 0,02 | X |
| | | 16дан артык | 0,02 | X |
| 3. | Су җылыткычлардан тыш, салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү үзәкләштерелгән, | 1дән 5кә кадәр | 0,03 | X |
| | | 6дан 9га | 0,02 | X |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | раковиналар, юынгычлар һәм унитазлар белән җиһазланды-рылган күпфатирлы йортлар | кадәр | | |
| | | 10нан 16га кадәр | 0,02 | X |
| | | 16дан артык | 0,02 | X |
| 4. | Үзәкләштерелгән су бүлүе булмаган салкын су белән тәэмин итү үзәкләштерелгән күпфатирлы йортлар | | 0,03 | X |